РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» сентября 2021г. г. Альметьевск № 83

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 3 өлеше нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 04 июлендәге 306, 2015 елның 13 мартындагы 455, 2015 елның 10 декабрендәге 40, 2017 елның 27 июлендәге 191, 2018 елның 11 маендагы 240, 2019 елның 25 мартындагы 286, 2019 елның 25 октябрендәге 330, 2020 елның 12 мартындагы 365, 2021 елның 11 мартындагы 46 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7. Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы,Россия Федерациясе гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы туктатылу-чит дәүләт гражданы яки Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә яшәвен раслый торган башка тәр документы булганда, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә, чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов